КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 23 июль г.Казань № 589

2024 елда «Казан (Идел буе) федераль университеты» югары белем бирү федераль дәүләт автоном мәгариф учреждениесенә, «Казан милли тикшеренү технология университеты» югары белем бирү федераль дәүләт бюджет мәгариф учреждениесенә, «А.Н.Туполев исемендәге Казан милли тикшеренү техник техник университеты – КАИ» югары белем бирү федераль дәүләт бюджет мәгариф учреждениесенә, «Югары нефть мәктәбе» Әлмәт дәүләт технология университеты югары белем бирү дәүләт бюджет мәгариф учреждениесенә һәм «Иннополис университеты» югары белем бирү автоном коммерциягә карамаган оешмасына «Алдынгы инженерлык мәктәпләрен үстерү программаларына ярдәм» субсидияләр рәвешендә грантлар бирү турында

Татарстан Республикасы Рәисенең «2024 елга «Алдынгы инженерлык мәктәпләрен үстерү программаларына ярдәм» грантын гамәлгә кую турында» 2024 елның 25 маендагы 388 номерлы Указы нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән 2024 елда «Казан (Идел буе) федераль университеты» югары белем бирү федераль дәүләт автоном мәгариф учреждениесенә, «Казан милли тикшеренү технология университеты» югары белем бирү федераль дәүләт бюджет мәгариф учреждениесенә, «А.Н.Туполев исемендәге Казан милли тикшеренү техник техник университеты – КАИ» югары белем бирү федераль дәүләт бюджет мәгариф учреждениесенә, «Югары нефть мәктәбе» Әлмәт дәүләт технология университеты югары белем бирү дәүләт бюджет мәгариф учреждениесенә һәм «Иннополис

университеты» югары белем бирү автоном коммерциягә карамаган оешмасына «Алдынгы инженерлык мәктәпләрен үстерү программаларына ярдәм» субсидияләр рәвешендә грантлар бирү тәртибен расларга.

2. Әлеге карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны «Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе» дәүләт фәнни бюджет учреждениесенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2024 ел, 23 июль, 589 нчы
карары белән расланды

2024 елда «Казан (Идел буе) федераль университеты» югары белем бирү федераль дәүләт автоном мәгариф учреждениесенә, «Казан милли тикшеренү технология университеты» югары белем бирү федераль дәүләт бюджет мәгариф учреждениесенә, «А.Н.Туполев исемендәге Казан милли тикшеренү техник техник университеты – КАИ» югары белем бирү федераль дәүләт бюджет мәгариф учреждениесенә, «Югары нефть мәктәбе» Әлмәт дәүләт технология университеты югары белем бирү дәүләт бюджет мәгариф учреждениесенә һәм «Иннополис университеты» югары белем бирү автоном коммерциягә карамаган оешмасына «Алдынгы инженерлык мәктәпләрен үстерү программаларына ярдәм» субсидияләр рәвешендә грантлар бирү
тәртибе

I. Гомуми нигезләмәләр

1. Әлеге Тәртип Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Юридик затларга, индивидуаль эшкуарларга, шулай ук товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр җитештерүче физик затларга Россия Федерациясе субъектлары бюджетларыннан, җирле бюджетлардан субсидияләр, шул исәптән субсидияләр рәвешендә грантлар бирүне һәм әлеге субсидияләрне, шул исәптән субсидияләр рәвешендә грантларны алучыларны сайлап алуны үткәрүне җайга сала торган норматив хокукый актларга, муниципаль хокукый актларга карата гомуми таләпләрне раслау турында» 2023 елның 25 октябрендәге 1782 номерлы карары, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы, Татарстан Республикасы Рәисенең «2024 елга «Алдынгы инженерлык мәктәпләрен үстерү программаларына ярдәм» грантын гамәлгә кую турында» 2024 елның 25 маендагы 388 номерлы Указы нигезендә эшләнде һәм 2024 елда алдынгы инженерлык мәктәпләрен үстерү программаларына ярдәм итүгә бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү өчен «Казан (Идел буе) федераль университеты» югары белем бирү федераль дәүләт автоном мәгариф учреждениесенә, «Казан милли тикшеренү технология университеты» федераль дәүләт бюджет югары белем бирү мәгариф учреждениесенә, «А.Н.Туполев исемендәге Казан милли тикшеренү техник техник университеты – КАИ» югары белем бирү федераль дәүләт бюджет мәгариф учреждениесенә, «Югары нефть мәктәбе» Әлмәт дәүләт технология университеты югары белем бирү дәүләт бюджет мәгариф учреждениесенә һәм «Иннополис университеты» югары белем бирү автоном коммерциягә карамаган оешмасына субсидияләр рәвешендә грантлар (алга таба – грант, югары белем бирү мәгариф оешмалары) бирү максатын, шартларын һәм тәртибен билгели.

2. Грант федераль проект кысаларында Татарстан Республикасында югары белем бирү буенча алдынгы мәгариф оешмалары базасында алдынгы инженерлык мәктәпләренең югары технологияле компанияләре белән партнерлыкта төзелгән,

инженерлык әзерлегенең яңа төрен булдыру, Россия Федерациясе технологик үсешенең өстенлекле өлкәләрендә алга киткән эшләнмәләрне һәм тикшеренүләрне гамәлгә ашыру, Татарстан Республикасының яңа икътисад тармакларын формалаштыру һәм үстерү өчен фәнни-технологик нигез булдыру, иң яхшы магистр программалары буенча талантлы студентлар өчен практикалар һәм стажировкалар (шул исәптән остазлар белән эшләү форматында) узу, алдынгы инженерлык мәктәпләренең, шулай ук инженерлык юнәлешендәге белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы югары белем бирү мәгариф оешмаларының профессор-мөгалимнәр составына һәм идарә итүче командаларына квалификация күтәрү һәм (яки) аларны яңадан һөнәри әзерләү (шул исәптән югары технологияле компанияләр базасында стажировка үтү рәвешендә) өчен шартлар тәэмин итүгә, шул исәптән түбәндәгеләргә юнәлдерелгән үсеш программаларына ярдәм күрсәтү максатларында бирелә:

а) инженерлык кадрларын әзерләү өчен инженерлык юнәлешендәге белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы алдынгы инженерлык мәктәпләренең һәм югары белем бирү мәгариф оешмаларының идарә итү командалары һәм профессор-мөгаллимнәр составы квалификациясен күтәрүгә һәм (яисә) яңадан һөнәри әзерләүгә (шул исәптән югары технологияле компанияләр базасында стажировка үтү рәвешендә);

б) инженерлык кадрларын алдан әзерләү өчен югары белем бирү буенча яңа мәгариф программаларын һәм алдан әзерләү буенча интерактив комплекслар белән тәэмин ителгән актуаль фәнни-технологик юнәлешләр һәм «үтәли» цифрлы технологияләр буенча өстәмә һөнәри программаларны эшләүгә һәм гамәлгә кертүгә;

в) Россия Федерациясе икътисадының югары җитештерүле секторында югары квалификацияле кадрлар әзерләү шартларын булдыруга һәм (яисә) камилләштерүгә, шулай ук эшләүче инженерларны алдынгы инженерлык мәктәпләрендә укыту эшчәнлеген гамәлгә ашыруга җәлеп итүгә;

г) алдынгы инженерлык мәктәпләре базасында махсус белем бирү киңлекләрен (лабораторияләр, тәҗрибә производстволары, алдан әзерлекле интерактив комплекслар, заманча югары технологияле җиһазлар, югары җитештерүчәнлекле исәпләү системалары һәм махсуслаштырылган гамәли программа тәэминаты белән җиһазландырылган цифрлы, «акыллы», виртуаль (киберфизик) фабрикалар) булдыруга;

д) югары технологияле компанияләр ярдәмендә һәм катнашында цифрлы икътисадның «үтәли» технологияләре, техника һәм технологияләр үсешенең өстенлекле юнәлешләре буенча фәнни-тикшеренү һәм тәҗрибә-конструкторлык проектлары базасында гамәлгә ашырыла торган технологик юнәлештәге магистратура программалары буенча белем алучы иң яхшы студентлар өчен белем бирү процессы кысаларыннан тыш практика һәм (яисә) стажировкалар узуга (шул исәптән остазлар белән эшләү форматында).

3. 2024 елда Россия Федерациясе бюджет законнары нигезендә бюджет акчасын алучы буларак грант бирүгә бюджет йөкләмәләре лимитлары билгеләнгән тәртиптә җиткерелгән Татарстан Республикасы бюджеты акчасы белән баш эш итүче – «Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе» дәүләт фәнни бюджет учреждениесе (алга таба – Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе).

Грант турында мәгълүмат «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Россия Федерациясе бюджет системасы бердәм порталының «Бюджет» бүлегендә Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә урнаштырыла.

4. Әлеге Тәртип максатларында түбәндәге төшенчәләр кулланыла:

алдынгы инженерлык мәктәбе – югары технологияле компанияләр белән партнерлыкта алдынгы инженерлык мәктәбен үстерү программасы нигезендә белем бирү, фәнни, инновацион эшчәнлекне гамәлгә ашыра торган югары белем бирү мәгариф оешмасының структур бүлекчәсе (юридик зат төземичә);

югары технологияле компания – Россия Федерациясе территориясендә Россия Федерациясе законнары нигезендә эш итүче, югары технологияле һәм фән сыйдырышлы тармакларда эшчәнлек алып баручы оешма.

## II. Грант бирү күләме һәм шартлары

5. Һәр югары белем бирү мәгариф оешмасына бирелә торган грант күләме 82 356,18 мең сум тәшкил итә.

6. Финанс белән тәэмин итү чыганагы грант булган чыгымнар юнәлешләренә түбәндәгеләр керә:

алдынгы инженерлык мәктәбе эшчәнлеген тәэмин итүгә җәлеп ителгән югары белем бирү мәгариф оешмалары хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү;

алдынгы инженерлык мәктәбе эшчәнлеген тәэмин итүгә җәлеп ителгән югары белем бирү мәгариф оешмалары хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү буенча түләүләргә исәпләүләр;

физик һәм юридик затларның әлеге Тәртипнең 2 пунктында каралган максатларны гамәлгә ашыру өчен кирәкле эшләре, хезмәт күрсәтүләре, шул исәптән элемтә хезмәтләре, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән файдалану, мәгълүмат технологияләре өлкәсендә хезмәт күрсәтүләр, программа тәэминатын эшләү өчен түләү;

алдынгы инженерлык мәктәбе эшчәнлеген тәэмин итүгә җәлеп ителгән югары белем бирү мәгариф оешмалары хезмәткәрләренә әлеге Тәртипнең 2 пунктында каралган, күмәк шартнамәдә, килешүләрдә, локаль норматив актларда, хезмәт шартнамәсендә билгеләнгән максатлар белән бәйле командировка чыгымнары өчен түләү;

әлеге Тәртипнең 2 пунктында каралган максатларны гамәлгә ашыру өчен кирәкле товарларны, башкарылмаган активларны, матди булмаган активларны, матди запасларны һәм төп чараларны (программа тәэминатын һәм җиһазлар сатып алуны кертеп) сатып алу;

белем алучыларга Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Стипедия фондын формалаштыру турында» 2016 елның 17 декабрендәге 1390 номерлы карарында күләмнәре билгеләнә торган стипендияләр һәм башка матди ярдәм формаларын түләү.

7. Грант бирү шартлары:

югары белем бирү мәгариф оешмаларының «Алгы инженерлык мәктәпләре»

мәгълүмат системасының https://lk.engineers2030.ru/ шәхси кабинетында электрон рәвештә төзелгән, формалаштырылган һәм җитәкченең яисә югары белем бирү мәгариф оешмасы исеменнән эш итәргә вәкаләтле затның квалификацияле электрон имзасы белән расланган түбәндәге бер яки берничә өстенлекле юнәлешләр буенча кимендә 7 елга (грант бирелә торган елны кертеп) алдынгы инженерлык мәктәбен үстерү программасы булу: «Интеллектуаль производстволар технологияләре», «Түбән / нульле углерод эзе булган автотранспорт», «Интеллектуаль автомобиль», «Материаллар технологиясе», «Цифрлы технологияләр», «Композитлы технологияләр», «Аддитив технологияләр», «Микроэлектроника һәм радиоэлектрон аппаратура», «Гамәли геология», «Тау эше», «Нефть-газ эше», «Геодезия», «Программа инженериясе» һәм «Ясалма интеллект һәм цифрлы технологияләр»;

югары белем бирү мәгариф оешмасы, шулай ук югары белем бирү мәгариф оешмасы белән төзелгән шартнамәләр нигезендә акча алучы башка юридик затлар тарафыннан Татарстан Республикасы бюджетыннан алынган чит ил валютасы акчасы исәбеннән, югары технологияле импорт җиһазларын, чималны һәм комплектлаучы әйберләрне сатып алганда (кайтартканда) Россия Федерациясенең валюта законнары нигезендә гамәлгә ашырыла торган операцияләрдән тыш, шулай ук әлеге Нигезләмәнең 6 пунктында билгеләнгән башка операцияләрне әлеге акчаны бирү нәтиҗәләренә ирешү белән бәйле, чит ил валютасы чараларын сатып алуга тыю;

югары белем бирү мәгариф оешмасының, югары белем бирү мәгариф оешмасы белән (дәүләт (муниципаль) унитар предприятиеләреннән, устав (җыелма) капиталларында гавами-хокукый берәмлекләр катнашында хуҗалык ширкәтләреннән һәм җәмгыятьләреннән, устав (җыелма) капиталларында әлеге ширкәтләрнең һәм җәмгыятьләрнең катнашуында коммерция оешмаларыннан тыш) төзелгән шартнамәләр нигезендә акча алучы затларның үзләренә карата Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе тарафыннан грант бирү тәртибе һәм шартлары (шул исәптән грант бирү нәтиҗәләренә ирешү өлешендә) үтәлешен тикшерүне гамәлгә ашыруга, шулай ук дәүләт финанс контроле органнары тарафыннан Россия Федерациясе Бюджет кодексының $268^1$ һәм $269^2$ статьялары нигезендә тикшерүгә һәм мондый нигезләмәләрне грант бирү турындагы килешүгә кертүгә ризалыгы;

югары технологияле компаниянең алдынгы инженерлык мәктәбен үстерүгә, шулай ук алдынгы инженерлык мәктәбен үстерү программасы чараларын гамәлгә ашыруны финанслашуга ярдәм күрсәтергә әзер булуын раслый торган документлар булу.

8. Югары белем бирү мәгариф оешмалары, грант бирүгә заявка (алга таба – заявка) тапшыру датасына кадәрге айның 1 еннән да соңга калмыйча, түбәндәге таләпләргә туры килергә тиеш:

бердәм салым исәбендә Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм иминият кертемнәре түләү буенча бурычы булмау яисә Россия Федерациясе Салым кодексының 47 статьясындагы 3 пунктында билгеләнгән күләмнән артмау;

башка субсидияләрне, бюджет инвестицияләрен Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтару буенча срогы чыккан бурычы, шулай ук Татарстан Республикасы алдында акчалата йөкләмәләр буенча башка срогы чыккан (җайга

салынмаган) бурычы булмау (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты билгеләгән очраклардан тыш);

үзгәртеп оештыру (югары белем бирү мәгариф оешмасына башка юридик затны кушу рәвешендә үзгәртеп оештырудан тыш), бетерү процессында булмау, аларга карата банкротлык процессы билгеләнмәү, югары белем бирү мәгариф оешмасы эшчәнлеге Россия Федерациясе законнарында каралган тәртиптә туктатылмау;

дисквалификацияләнгән затлар реестрында дисквалификацияләнгән җитәкчеләр, коллегиаль башкарма орган әгъзалары, бер кеше башкара торган башкарма орган функциясен үтәүче зат яки югары белем бирү мәгариф оешмасының баш бухгалтеры турында мәгълүматлар булмау;

чит ил, шул исәптән теркәлү урыны Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан раслана торган, Россия Федерациясендә активларга арадаш (офшор) ия булу өчен файдаланыла торган дәүләтләр һәм территорияләр (алга таба – офшор компанияләре) исемлегенә кертелгән дәүләт яки территория булган юридик заты, шулай ук устав (җыелма) капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры яки турыдан-туры булмаган (өченче затлар аша) катнашу өлеше барысы бергә 25 проценттан арткан Россия юридик заты (әгәр Россия Федерациясе законында башкасы каралмаса) булып тормау. Офшор компанияләренең Россия юридик затлары капиталында катнашу өлешен исәпләп чыгарганда акцияләре Россия Федерациясендәге оештырылган торгларда әйләнештә йөри торган гавами (шул исәптән халыкара компания статусы булган) акционерлык җәмгыятьләре капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры һәм (яки) турыдан-туры булмаган катнашуы, шулай ук мондый офшор компанияләренең башка Россия юридик затлары капиталында әлеге гавами акционерлык җәмгыятьләре капиталында катнашып тормышка ашырылган турыдан-туры булмаган катнашуы исәпкә алынмый;

әлеге Тәртипнең 2 пунктында күрсәтелгән максатларга Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары нигезендә акча алмау;

экстремистик эшчәнлеккә яки террорчылыкка катнашы барлыгы турында белешмәләр булган оешмалар һәм физик затлар исемлегендә тормау;

БМО уставының VII бүлегендә каралган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру кысаларында БМО Куркынычсызлык Советы яки БМО Куркынычсызлык Советы карарлары белән махсус оештырылган органнар тарафыннан төзелә торган террорчылык оешмалары һәм террорчылар белән яки массакүләм юк итү коралын тарату белән бәйле оешмалар һәм физик затлар исемлегендә тормау;

«Чит ил йогынтысында булган затлар эшчәнлеген контрольдә тоту турында» 2022 елның 14 июлендәге 255-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә чит ил агенты булып тормау;

9. Грант алу өчен югары белем бирү мәгариф оешмалары Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенә әлеге Тәртипнең кушымтасында бирелгән форма буенча, шул исәптән әлеге Тәртипнең 7 пунктында күрсәтелгән алдынгы инженерлык мәктәбенең өстенлекле юнәлеше исемен, грант күләмен күрсәтеп, заявка, шулай ук җитәкче яисә югары белем бирү мәгариф оешмасы исеменнән эш итәргә вәкаләтле зат тарафыннан таныкланган түбәндәге документларны тапшыра:

а) «Алдынгы инженерлык мәктәпләре» мәгълүмат системасының шәхси кабинетында https://lk.engineers2030.ru/ электрон төрдә эшләнгән, югары белем бирү мәгариф оешмасы җитәкчесенең яки әлеге оешма исеменнән эш итәргә вәкаләтле затның квалификацияле электрон имзасы белән формалаштырылган һәм расланган кимендә 7 елга (грант бирелә торган елны да кертеп) алдынгы инженерлык мәктәбен үстерү программасы күчермәсен;

б) югары технологияле компания тарафыннан алдынгы инженерлык мәктәбен үстерү программасы чараларын гамәлгә ашыруны финанслашу күләмен раслый торган белешмә кәгазен;

в) устав күчермәсен;

г) Федераль салым хезмәтенең «Салым түләүченең (җыюны түләүче, иминият кертемнәрен түләүче, салым агенты) тарафыннан салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар һәм аны электрон рәвештә тапшыру форматының үтәлеше турында белешмә формасын раслау турында» 2022 елның 23 ноябрендәге ЕД-7-8/1123@ номерлы боерыгы белән расланган форма буенча телекоммуникация элемтә каналлары буенча яки салым түләүченең шәхси кабинеты аша электрон формада яисә кәгазьдә салым органы мәгълүматлары нигезендә белешмә кәгазен формалаштыру датасына карата салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча йөкләмәләрнең үтәлеше турында белешмә кәгазен;

д) югары белем бирү мәгариф оешмасының үзгәртеп оештыру (югары белем бирү мәгариф оешмасына башка юридик затны кушу формасында үзгәртеп оештырудан тыш), бетерү процессында тормавы, югары белем бирү мәгариф оешмасына карата банкротлык процедурасы билгеләнмәве, югары белем бирү мәгариф оешмасы эшчәнлеге Россия Федерациясе законнарында каралган тәртиптә туктатылмавы турында югары белем бирү мәгариф оешмасы җитәкчесе тарафыннан имзаланган гарантия хатын;

е) коллегиаль башкарма орган җитәкчесенә, әгъзаларына, бер генә кеше идарә итә торган башкарма орган функцияләрен башкаручы затка яки югары белем бирү мәгариф оешмасының баш бухгалтерына (баш бухгалтеры булганда) Федераль салым хезмәтенең «Дисквалификацияләнгән затлар реестрындагы мәгълүматларны бирү тәртибен, дисквалификацияләнгән затлар реестрыннан өземтә һәм соратып алына торган мәгълүматның булмавы турында белешмә кәгазе формаларын раслау хакында» 2014 елның 31 декабрендәге НД-7-14/700@ номерлы боерыгы белән расланган формалар буенча дисквалификацияләнгән затлар реестрыннан өземтә һәм (яки) соратыла торган мәгълүматның булмавы турында белешмә кәгазен;

ж) югары белем бирү мәгариф оешмасының чит ил юридик заты, шул исәптән офшор компаниясе, шулай ук устав (җыелма) капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры яки турыдан-туры булмаган (өченче затлар аша) катнашу өлеше барысы бергә 25 проценттан арткан Россия юридик заты (әгәр Россия Федерациясе законында башкасы каралмаса) булмавын раслый торган, югары белем бирү мәгариф оешмасының җитәкчесе тарафыннан кул куелган гарантия хатын;

з) югары белем бирү мәгариф оешмасы җитәкчесе тарафыннан кул куелган, югары белем бирү мәгариф оешмасының «Чит ил йогынтысында булган затлар

эшчәнлеген контрольдә тоту турында» 2022 елның 14 июлендәге 255-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә чит ил агенты булмавын раслый торган гарантия хатын;

и) югары белем бирү мәгариф оешмасы җитәкчесе тарафыннан кул куелган, югары белем бирү мәгариф оешмасының әлеге Тәртипнең 2 пунктында күрсәтелгән максатлар өчен Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары нигезендә Татарстан Республикасы бюджетыннан акча алмавын раслый торган гарантия хатын;

к) югары белем бирү мәгариф оешмасы җитәкчесе тарафыннан кул куелган, югары белем бирү мәгариф оешмасының башка субсидияләрне, бюджет инвестицияләрен Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтару буенча срогы чыккан бурычы, шулай ук Татарстан Республикасы алдындагы акчалата йөкләмәләр буенча срогы чыккан (җайга салынмаган) башка бурычы (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнгән очраклардан тыш) булмавын раслый торган гарантия хатын;

л) Финанс мониторингы федераль хезмәте тарафыннан төзелә торган экстремистик эшчәнлеккә яки террорчылыкка катнашы булуы турында мәгълүмат бирелгән оешмалар һәм физик затлар исемлегеннән һәм террорчылык оешмалары һәм террорчылар белән бәйле яисә массакүләм юк итү коралын таратуга бәйле оешмалар һәм физик затлар исемлегеннән әлеге исемлекләрдә югары белем бирү мәгариф оешмасының булмавы турында белешмәләрне.

Югары белем бирү мәгариф оешмасы әлеге пунктның «а», «г», «е» һәм «л» пунктчаларында күрсәтелгән документларны тапшырмаган очракта, Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе әлеге документларны ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек тәртибендә соратып ала.

Һәрбер югары белем бирү мәгариф оешмасы иң күбе бер генә заявка бирергә хокуклы.

10. Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенә кергән заявка кергән көненнән алып бер эш көне эчендә теркәүгә алына.

Документлар югары белем бирү мәгариф оешмасының вәкаләтле вәкиле яисә Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең урнашу урыны буенча почта аша кәгазьдә тапшырыла.

Кәгазьдәге заявка составында тапшырылган документлар аңа теркәлә торган исемлеккә кертелергә тиеш, исемлектә каралган тәртип буенча тегелгән, номерланган һәм югары белем бирү мәгариф оешмасы җитәкчесе яисә югары белем бирү мәгариф оешмасы исеменнән эш итәргә вәкаләтле зат имзасы белән расланган булырга тиеш.

11. Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе заявка кергән көннән алып эш көннәрендә исәпләнә торган биш көн эчендә:

заявканың әлеге Тәртипнең 7 һәм 8 пунктларында билгеләнгән шартларга һәм таләпләргә туры килүен карап тикшерә;

грант бирү һәм грант бирү турында килешү төзү хакында яисә грант бирүдән баш тарту турында карар кабул итә.

12. Югары белем бирү мәгариф оешмасына грант бирүдән баш тарту өчен нигезләр:

югары белем бирү мәгариф оешмасы тарафыннан тапшырылган документларның әлеге Тәртип белән билгеләнгән таләпләргә туры килмәве яисә күрсәтелгән

документларның тапшырылмавы (әлеге Тәртипнең 9 пунктындагы «а», «г», «е», «л» пунктчаларында күрсәтелгән документлардан тыш);

югары белем бирү мәгариф оешмасы тарафыннан тапшырылган мәгълүматның дөрес булмау факты билгеләнү.

13. Грант бирүдән баш тарту турында карар кабул ителгән очракта, Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенә тиешле карар кабул ителгән көннән алып биш көн эчендә бу турыда югары белем бирү мәгариф оешмасына хәбәр итә. Грант бирүдән баш тарту турында карарда баш тарту сәбәпләре күрсәтелергә тиеш.

14. Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең грант бирү һәм грант бирү турында килешү төзү хакындагы карары Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе президенты боерыгы белән рәсмиләштерелә.

## III. Грант бирү тәртибе

15. Грант бирү өчен нигез – Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе белән югары белем бирү мәгариф оешмасы белән арасында, Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе тарафыннан грант бирү турында карар кабул ителгән көннән 10 эш көненнән дә соңга калмыйча, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы билгеләгән бертип форма нигезендә төзелә торган грант бирү турында килешү.

16. Грант бирү турындагы килешүдә түбәндәгеләр карала:

грант бирү максаты;

грант күләме;

грантны күчерү сроклары һәм тәртибе;

грант бирү нәтиҗәсе күрсәткечләренә ирешү турында хисап һәм финанс белән тәэмин итү чыганагы субсидия булган чыгымнарны гамәлгә ашыру турында хисап бирү формасы һәм сроклары;

электрон рәвештә һәм кәгазьдә төзелгән һәм югары белем бирү мәгариф оешмасы җитәкчесе яисә югары белем бирүче мәгариф оешмасы исеменнән эш итәргә вәкаләтле зат тарафыннан имзаланган 2024 елга алдынгы инженерлык мәктәбенең фәнни һәм мәгариф проектларының сыйфатын яхшырту программасын үтәү турында хисап бирү сроклары һәм формалары;

грант бирү тәмамлана торган төгәл дата һәм грант бирү нәтиҗәсенең соңгы күрсәткече (йомгакларның конкрет микъдари тасвирнамәсе);

югары белем бирү мәгариф оешмасының әлеге Тәртипнең 7 пунктында билгеләнгән грант бирү шартларын үтәү турында йөкләмәсе;

грантны кире кайтару тәртибе һәм сроклары;

грантны мәҗбүри түләтү буенча чаралар кабул итү сроклары;

грант бирү шартларын һәм тәртибен бозган өчен җаваплылык;

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән килешүнең бертип формаларында билгеләнгән формалар буенча грант бирү турындагы килешүгә өстәмә килешү, шул исәптән грант бирү турында килешүне өзү турында өстәмә килешү төзү шарты һәм тәртибе;

әлеге Тәртипнең 3 пунктында күрсәтелгән, элек җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе киметелгән очракта, грант бирү турындагы килешүдә билгеләнгән күләмдә бирү мөмкин

булмавына китерә торган грант бирү турындагы килешүнең яңа шартларын килештерү яки, яңа шартлар белән килешеп булмаганда, грант бирү турындагы килешүне өзү турында шарт;

2024 елда грантның файдаланылмый калган өлешен 2025 елда кире кайтару тәртибе һәм очраклары, 2024 елда финанс белән тәэмин итү чыганагы файдаланылмаган калган грант өлеше булган чыгымнарны гамәлгә ашыру мөмкинлеге карала торган шарт;

югары белем бирү мәгариф оешмасы, шулай ук югары белем бирү мәгариф оешмасы белән төзелгән шартнамәләр нигезендә акча алучы башка юридик затлар тарафыннан Татарстан Республикасы бюджетыннан алынган чит ил валютасы акчасы исәбеннән, югары технологияле импорт җиһазларын, чималны һәм комплектлаучы әйберләрне сатып алганда (кайтартканда) Россия Федерациясенең валюта законнары нигезендә гамәлгә ашырыла торган операцияләрдән тыш, шулай ук әлеге Нигезләмәнең 6 пунктында билгеләнгән башка операцияләрне әлеге акчаны бирү нәтиҗәләренә ирешү белән бәйле, чит ил валютасы чараларын сатып алуга тыю;

югары белем бирү мәгариф оешмасының, югары белем бирү мәгариф оешмасы белән (дәүләт (муниципаль) унитар предприятиеләреннән, устав (җыелма) капиталларында гавами-хокукый берәмлекләр катнашында хуҗалык ширкәтләреннән һәм җәмгыятьләреннән, устав (җыелма) капиталларында әлеге ширкәтләрнең һәм җәмгыятьләрнең катнашуында коммерция оешмаларыннан тыш) төзелгән шартнамәләр нигезендә акча алучы затларның үзләренә карата Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе тарафыннан грант бирү тәртибе һәм шартлары (шул исәптән грант бирү нәтиҗәләренә ирешү өлешендә) үтәлешен тикшерүне гамәлгә ашыруга, шулай ук дәүләт финанс контроле органнары тарафыннан Россия Федерациясе Бюджет кодексының $268^1$ һәм $269^2$ статьялары нигезендә тикшерүгә ризалыгы.

Югары белем бирү мәгариф оешмасы кушылу, кушу яки яңадан кору формасында үзгәртеп оештырылганда, грант бирү турындагы килешүдә югары белем бирү мәгариф оешмасының хокук варисы булып торган юридик зат күрсәтелеп, йөкләмәдәге затны алыштыру өлешендә грант бирү турындагы килешүгә өстәмә килешү төзү юлы белән үзгәреш кертелә.

Югары белем бирү мәгариф оешмасы аеру, бүлеп бирү рәвешендә үзгәртеп оештырылганда, шулай ук югары белем бирү мәгариф оешмасы бетерелгәндә грант бирү турындагы килешү бер яклы тәртиптә грант бирү турындагы килешүне өзү турында хәбәрнамә язып һәм грант бирү турындагы килешү буенча йөкләмәләрне башкару турында акт төзеп өзелә; әлеге актта югары белем бирү мәгариф оешмасы тарафыннан финанс белән тәэмин итү чыганагы грант булган, үтәлмәгән йөкләмәләр турында һәм грантның файдаланылмый калган өлешен Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтару турында мәгълүмат чагылдырыла.

17. Грант бирү турында карар кабул ителгән көннән алып эш көннәрендә исәпләнә торган өч көн эчендә грант бирү турында килешү проекты Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе тарафыннан югары белем бирү мәгариф оешмасына ул аңа Татарстан Республикасы Фәннәр академиясеннән грант бирү турында килешү проектын алган көннән алып эш көннәрендә исәпләнә торган биш көн эчендә имза кую өчен җибәрелә.

Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе ягыннан грант бирү турындагы

килешүгә югары белем бирү оешмасыннан аның тарафыннан имзаланган грант бирү турында килешү алынган көннән алып эш көннәрендә исәпләнә торган ике көн эчендә имзалана.

Әгәр югары белем бирү мәгариф оешмалары тарафыннан грант бирү турындагы килешүгә әлеге пунктның беренче абзацында күрсәтелгән срок эчендә кул куелмаган булса, алар грант бирү турындагы килешү төзүдән баш тарткан дип санала.

18. Грант Россия Федерациясе Үзәк банкы учреждениесендә яисә кредит оешмасында югары белем бирү оешмасы тарафыннан ачылган исәп-хисап яисә корреспондент счетына грант бирү турында карар кабул ителгән көннән алып 10 эш көненнән дә соңга калмыйча югары белем бирү оешмаларына күчерелә.

19. Югары белем бирү мәгариф оешмалары түбәндәге күрсәткечләргә ирешү 2024 елда югары белем бирү мәгариф оешмаларына грант бирү нәтиҗәсе булып торырга тиеш:

а) инженерлык кадрларын әзерләү өчен югары белем бирү белгечлекләре һәм юнәлешләре буенча инженерлык юнәлешендәге белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы алдынгы инженерлык мәктәпләренең һәм югары белем бирү мәгариф оешмаларының идарә итү командалары һәм профессор-мөгаллимнәр составының кимендә 25 кешесенә квалификациясен күтәрүне һәм (яисә) яңадан һөнәри әзерләүне (шул исәптән югары технологияле компанияләр базасында стажировка үтү рәвешендә) үткәрү;

б) инженерлык кадрларын алдан әзерләү өчен югары белем бирү буенча яңа мәгариф программаларын һәм алдан әзерләү буенча интерактив комплекслар белән тәэмин ителгән актуаль фәнни-технологик юнәлешләр һәм «үтәли» цифрлы технологияләр буенча эшләнгән һәм гамәлгә кертелгән югары белем бирүнең яңа мәгариф программалары саны кимендә 4 берәмлек тәшкил итәргә тиеш;

в) алдынгы инженерлык мәктәпләре тарафыннан гамәлгә ашырыла торган алдынгы инженерлык мәктәпләренең магистратура программалары буенча белем алучылар саны 15 кешедән ким булмаска тиеш;

г) алдынгы инженерлык мәктәбе базасында төзелгән махсус белем бирү пространстволары саны (фәнни-технологик һәм эксперименталь лабораторияләр, заманча югары технологияле җиһазлар, югары җитештерүчәнлекле исәпләү системалары һәм махсус гамәли программа тәэминаты белән җиһазландырылган тәҗрибәле җитештерүләр, цифрлы, «акыллы», виртуаль (киберфизик) фабрикалар, заманча цифрлы технологияләр нигезендә инженерлык кадрларын алдан әзерләүнең интерактив комплекслары) кимендә бер берәмлек тәшкил итәргә тиеш;

д) белем бирү барышы кысаларыннан тыш, шул исәптән остазлар белән эшләү форматында практика һәм (яки) стажировка узган студентлар, технологик профильдәге магистратура программалары буенча белем алучылар саны кимендә җиде кеше булырга тиеш;

е) алдынгы инженерлык мәктәбенең фәнни һәм мәгариф проектларының сыйфатын яхшырту буенча эшләнгән һәм Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе белән килештерелгән программалар саны кимендә бер берәмлек тәшкил итәргә тиеш.

## IV. Йомгаклау нигезләмәләре

20. Югары белем бирү мәгариф оешмалары квартал саен, хисап кварталыннан соң килә торган айның 15 енә кадәр, шулай ук хисап елыннан соң килә торган елның 15 гыйнварына кадәр Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенә Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән килешүнең бертип формасында билгеләнгән бертип формалар буенча грант бирү нәтиҗәсе күрсәткечләренә ирешү турында хисап һәм финанс белән тәэмин итү чыганагы грант булган чыгымнарны гамәлгә ашыру турында хисап тапшыра.

Югары белем бирү мәгариф оешмалары әлеге пунктның беренче абзацында күрсәтелгән срокларда Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенә электрон рәвештә һәм кәгазьдә эшләнгән һәм югары белем бирү мәгариф оешмасы җитәкчесе яки югары белем бирү мәгариф оешмасы исеменнән эш итәргә вәкаләтле зат тарафыннан имзаланган 2024 елга алдынгы инженерлык мәктәбенең фәнни һәм мәгариф проектлары сыйфатын яхшырту программасын үтәү турында хисап кертә.

Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе әлеге пунктның беренче һәм икенче абзацларында күрсәтелгән хисапларны алар тапшырылган көннән алып 10 эш көненнән артмаган срокта тикшерүне гамәлгә ашыра.

21. Финанс белән тәэмин итү чыганагы грант булган, 2024 елда файдаланылмаган акчаның калган өлеше 2025 елның 1 февраленә кадәр Татарстан Республикасы бюджеты кеременә (Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе тарафыннан, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы белән килештереп, грант бирү турында килешүдә билгеләнгән тәртиптә әлеге акчага ихтыяҗ булу турында карар кабул ителгән очраклардан тыш) кире кайтарылырга тиеш.

Хисап финанс елында файдаланылмаган акчаны тотуга ихтыяҗ булган очракта, әлеге Тәртипнең 2 пунктында күрсәтелгән максатлар өчен югары белем бирү мәгариф оешмасы Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенә, хисап елыннан соң килә торган елның 15 гыйнварыннан да соңга калмыйча, шундый ихтыяҗны нигезләп, мәгълүмат бирә.

Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе, әлеге пунктның икенче абзацында күрсәтелгән мәгълүматны югары белем бирү мәгариф оешмасыннан алган көннән алып 10 календарь көннән дә соңга калмыйча, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы белән килештереп, агымдагы финанс елында хисап финанс елында файдаланылмаган грантның калган өлешен тотуга ихтыяҗ булу яки булмау турында карар кабул итә.

Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе тарафыннан агымдагы финанс елында хисап финанс елында файдаланылмаган грантның калган өлешен тотуга ихтыяҗ булу турында карар кабул ителгән очракта, Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе һәм югары белем бирү мәгариф оешмасы арасында мондый карар кабул ителгән көннән алып эш көннәрендә исәпләнә торган өч көн эчендә Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы билгеләгән форма буенча грант бирү турындагы килешүләргә өстәмә килешүләр төзелә.

22. Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе югары белем бирү мәгариф

оешмаларының грант бирү шартларын һәм тәртибен (шул исәптән грант бирү нәтиҗәсенә ирешү өлешендә) үтәвен тикшерүне гамәлгә ашыра. Дәүләт финанс контроле органнары Россия Федерациясе Бюджет кодексының $268^{1}$ һәм $269^{2}$ статьялары нигезендә тикшерү үткәрүне гамәлгә ашыра.

Грант бирү турында килешүдә билгеләнгән грант бирү нәтиҗәсенең күрсәткечләренә ирешүне һәм субсидия бирү нәтиҗәсен алу буенча тиешле чара тәмамлану фактын чагылдыра торган вакыйгаларны (контроль нокта) мониторинглау Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе тарафыннан нәтиҗәләргә ирешүне мониторинглау тәртибендә билгеләнгән тәртиптә һәм формалар буенча уздырыла.

23. Югары белем бирү мәгариф оешмасы тарафыннан грант бирү шартлары һәм тәртибе бозылган, шул исәптән Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе һәм дәүләт финанс контроле органнары үткәргән тикшерүләр фактлары буенча ачыкланган бозылышлар булган очракта, шулай ук әлеге Тәртипнең 19 пунктында күрсәтелгән грант бирү нәтиҗәләре күрсәткечләренә ирешмәгән очракта, югары белем бирү мәгариф оешмасы Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең язма таләбен алган көннән алып 30 календарь көн эчендә алынган акчаны тулы күләмдә Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтаруны гамәлгә ашыра.

24. Әлеге Тәртипнең 21 һәм 23 пунктларында күрсәтелгән акчаны Татарстан Республикасы бюджеты кеременә ирекле рәвештә кире кайтарудан баш тартылган очракта, Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе югары белем бирү мәгариф оешмасы тарафыннан Татарстан Республикасы бюджетына алынган акчаны кире кайтарудан баш тарту турында хәбәр алынган көннән яки Россия Федерациясе законнары нигезендә алынган акчаны Татарстан Республикасы бюджетына Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең язма таләбендә күрсәтелгән ирекле рәвештә кире кайтару срогы чykkannan соң календарь көннәрдә исәпләнә торган җиде көн эчендә мәҗбүри тәртиптә түләтү буенча чаралар күрә.

25. Гранттан нәтиҗәле файдалануны, аны бирү шартларын һәм тәртибен үтәүне контрольдә тоту Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе тарафыннан гамәлгә ашырыла.

2024 елда «Казан (Идел буе) федераль университеты» югары белем бирү федераль дәүләт автоном мәгариф учреждениесенә, «Казан милли тикшеренү технология университеты» югары белем бирү федераль дәүләт бюджет мәгариф учреждениесенә, «Казан милли тикшеренү технология университеты» федераль дәүләт бюджет югары белем бирү мәгариф учреждениесенә, «А.Н.Туполев исемендәге Казан милли тикшеренү техник техник университеты – КАИ» югары белем бирү федераль дәүләт бюджет мәгариф учреждениесенә, «Югары нефть мәктәбе» Әлмәт дәүләт технология университеты югары белем бирү дәүләт бюджет мәгариф учреждениесенә һәм «Иннополис университеты» югары белем бирү автоном коммерциягә карамаган оешмасына «Алдынгы инженерлык мәктәпләрен үстерү программаларына ярдәм» субсидияләр рәвешендә грантлар бирү тәртибенә кушымта

Форма

Теркәү номеры:
Заявканы теркәү датасы:

2024 елда «Казан (Идел буе) федераль университеты» югары белем бирү федераль дәүләт автоном мәгариф учреждениесенә, «Казан милли тикшеренү технология университеты» югары белем бирү федераль дәүләт бюджет мәгариф учреждениесенә, «А.Н.Туполев исемендәге Казан милли тикшеренү техник университеты – КАИ» югары белем бирү федераль дәүләт бюджет мәгариф учреждениесенә, «Югары нефть мәктәбе» Әлмәт дәүләт технология университеты югары белем бирү дәүләт бюджет мәгариф учреждениесенә һәм «Иннополис университеты» югары белем бирү автоном коммерциягә карамаган оешмасына «Алдынгы инженерлык мәктәпләрен үстерү программаларына ярдәм» субсидияләр рәвешендә грантлар бирүгә
заявка

| Заявка бирүченең исеме | Җитәкченең фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булганда) | Заявка бирүченең урнашу урыны, телефоны, электрон адресы |
| --- | --- | --- |
| | | |

Грант күләме: ________________________________________________________.
Алдынгы инженерлык мәктәбенең өстенлекле юнәлеше исеме: ___________________
________________________________________________________________________.

Әлеге заявка белән заявка бирүче Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2024 елда «Казан (Идел буе) федераль университеты» югары белем бирү федераль дәүләт автоном мәгариф учреждениесенә, «Казан милли тикшеренү технология университеты» югары белем бирү федераль дәүләт бюджет мәгариф учреждениесенә, «Казан милли тикшеренү технология университеты» югары белем бирү федераль дәүләт бюджет мәгариф учреждениесенә, «А.Н.Туполев исемендәге Казан милли тикшеренү техник техник университеты – КАИ» югары белем бирү федераль дәүләт бюджет мәгариф учреждениесенә, «Югары нефть мәктәбе» Әлмәт дәүләт технология университеты югары белем бирү дәүләт бюджет мәгариф учреждениесенә һәм «Иннополис университеты» югары белем бирү автоном коммерциягә карамаган оешмасына «Алдынгы инженерлык мәктәпләрен үстерү программаларына ярдәм» субсидияләр рәвешендә грантлар бирү турында» 2024 ел, 23 июль, 589 нчы карары белән расланган 2024 елда «Казан (Идел буе) федераль университеты» югары белем бирү федераль дәүләт автоном мәгариф учреждениесенә, «Казан милли тикшеренү технология университеты» югары белем бирү федераль дәүләт бюджет мәгариф учреждениесенә, «Казан милли тикшеренү технология университеты» югары белем бирү федераль дәүләт бюджет мәгариф учреждениесенә, «А.Н.Туполев исемендәге Казан милли тикшеренү техник техник университеты – КАИ» югары белем бирү федераль дәүләт бюджет мәгариф учреждениесенә, «Югары нефть мәктәбе» Әлмәт дәүләт технология университеты югары белем бирү дәүләт бюджет мәгариф учреждениесенә һәм «Иннополис университеты» югары белем бирү автоном коммерциягә карамаган оешмасына «Алдынгы инженерлык мәктәпләрен үстерү программаларына ярдәм» субсидияләр рәвешендә грантлар бирү тәртибенең 8 пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килүен раслый һәм Тәртипнең 7 пункты нигезендә үзенә, шулай ук югары белем бирү мәгариф оешмасы (дәүләт (муниципаль) унитар предприятиеләреннән, устав (җыелма) капиталларында гавами-хокукый берәмлекләр катнашында хуҗалык ширкәтләре һәм җәмгыятьләр, шулай ук устав (җыелма) капиталларында мондый ширкәтләр һәм җәмгыятьләр катнашында коммерция оешмаларыннан тыш) белән төзелгән шартнамәләр нигезендә акча алучы затларга карата Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе тарафыннан грант бирү тәртибе һәм шартлары үтәлешен (шул исәптән грант бирү нәтиҗәләренә ирешү өлешендә) тикшерүне, шулай ук дәүләт финанс контроле органнары тарафыннан Россия Федерациясе Бюджет кодексының $268^1$ һәм $269^2$ статьялары нигезендә тикшерүне гамәлгә ашыруга һәм мондый нигезләмәләрне грант бирү турындагы килешүгә кертүгә үз ризалыгын белдерә.

Кушымталар: 1.
2.

| Заявка бирүче | ______________________<br>(заявка бирүченең исеме) | ______________________<br>(җитәкченең фамилиясе, инициаллары) | ______________________<br>(имза) |
|---|---|---|---|

______________________________